РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.07.2018 Буа шәһәре № 185/ИК-п

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ
регламентларын раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, Буа муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1.Яңа редакциядә расларга:

1.1. «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын ( 2 нче кушымта).

1.3. Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (3 нче кушымта).

1.4. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм аларга тиңләштерелгән затларга радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга һәм Дәүләт торак сертификатын исәпкә кую һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (4 нче кушымта).

1.5. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күченеп килергә мәҗбүр булганнарга торак сатып алуга субсидияләр бирү өчен дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (5 нче кушымта).

1.6. Торак урыны, муниципаль торак фонды, гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (6 нчы кушымта).

1.7. Торак урынын, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (7 нче кушымта).

1.8. Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (8 нче кушымта).

1.9. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (9 нчы кушымта).

1.10. Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (10 нчы кушымта).

1.11. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (11 нче кушымта).

1.12. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (12 нче кушымта).

1.13. Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (13 нче кушымта).

1.14. Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (14 нче кушымта).

1.15. Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (15 нче кушымта).

1.16. Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (16 нчы кушымта).

1.17. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (17 нче кушымта).

1.18. Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (18 нче кушымта).

1.19. Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты: васыятьнамә таныклыгы яки ышанычнамә таныклыгын (19 нчы кушымта).

1.20. Социаль түләүләрне файдаланып, торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлегенә кертү һәм авыл җирлегендә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләү бирү турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (20 нче кушымта)

1.21. Ана (гаилә) капиталы средстволарын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне башкаруны раслаучы документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (21 нче кушымта).

2. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 01 июлендәге 286-п номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Буа муниципаль районы башкарма комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә өч эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 1 пунктта расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә

4. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук муниципаль берәмлекләр порталында, Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган вакыттан законлы көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе М.М. Юнысовага йөкләргә.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Камартдинов